СОВЕТ КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Киров урамы, 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422177

Тел. (факс): (85563) 2-72-03 e-mail: Katmish..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

**Решение** **Карар**

«02» октябрь 2017 ел №1-26

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьясына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 23.03.2004 №23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитетының 20.09.2017 ел №15 санлы "Референдум үткәрү инициативасы турында" гы карары нигезендә ", Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 20.09.2017 ел 2-25 санлы “Референдум үткәрү инициативасы турында” карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2018 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш

хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнар күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:
Катмыш торак пунктының су белән тәэмин итү системасын капиталь ремонтлау - Ленин урамы, Гагарин урамы;
су белән тәэмин итү системасын ремонтлау Баскан торак пункты, Еникей Чишмә торак пунктында
су чыганагыннан (чишмәдән) су белән тәэмин итү линиясен үткәрү һәм Катмыш торак пунктын үзәк су белән тәэмин итү системасына кушу, су күтәрү манарасын сатып алу һәм урнаштыру
2. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:
Баскан һәм Катмыш торак пунктларында Җиңү һәм ял паркын төзекләндерү.

"ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы И.Г Габидуллинга йөкләргә

Катмыш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Г. Габидуллин